| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.12.2014 Казан ш. № 4-2/г

***Татарстан Республикасында көнкүреш ихтыяҗлары өчен халыкка сатыла торган суытылган сыек газга, 2015 елга ваклап сату бәяләрен билгеләү турында***

“Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында” 1999 елның 31 март № 69-ФЗ Федераль законына, “Газга һәм аны җитештерү чималына бәяләрне дәүләт көйләвен тәртипкә салу чаралары турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1995 елның 15 апрель № 332 карарына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 26 сентябрь утырышында хупланган “Россия Федерациясенең 2015 елга һәм 2016-2017 елларга план чорына социаль-иктисади үсеше Фаразлары”на., “Халыкка көнкүреш ихтыяҗларына сату өчен суытылган сыек газны ваклап сату бәяләрен көйләү буенча Методик күрсәтмәләрне раслау турында” тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2007 елның 15 июнь № 129-э/2 боерыгына, Татарстан республикасының тарифлар буенча Дәүләт комитеты турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 15.06.2010 № 468 карары белән раслаган Нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасының тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы халкына көнкүреш ихтыяҗларына сатыла торган суытылган сыек газга (НДСны исәпкә алып), календарга бүлеп, ваклап сату бәяләрен мондый күләмнәрдә билгеләргә:

1.1. 2015 елның 1 гыйнварыннан 2015 елның 30 июненә кадәр:

- газны кулланучыларга җиткерүдә транспорт чыгымнары бәясен исәпкә алмыйча, 1 килограммы 24,28 сум,

- газны кулланучыларга җиткерүдә транспорт чыгымнары бәясен исәпкә алып, 1 килограммы 28,13 сум.

1.2. 2015 елның 1 июленнән 2015 елның 31 декабренә кадәр:

- газны кулланучыларга җиткерүдә транспорт чыгымнары бәясен исәпкә алмыйча, 1 килограммы 26,10 сум,

- газны кулланучыларга җиткерүдә транспорт чыгымнары бәясен исәпкә алып, 1 килограммы 30,24 сум.

2. Шушы карар рәсми басылгач, ун көннән соң, үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифларбуенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов